КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 16 май г.Казань № б-1073

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 25 декабрендәге б-3183 номерлы боерыгының 3 пунктын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә климат үзгәрүенә җайлашу планын (алга таба – План) расларга.
2. Планны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнар тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында баш эш итүчеләргә каралган бюджет ассигнованиеләре, муниципаль берәмлекләр бюджетлары чикләрендә, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын План чараларын гамәлгә ашыруны координацияләү органы итеп билгеләргә.
4. Планны гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына җавап бирә торган тармакларның (юнәлешләрнең) төп чараларын гамәлгә ашыру планнарын расларга һәм ел саен, 1 мартка кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җавап бирә торган тармаклар (юнәлешләр) буенча План чараларын үтәү барышы турында хисаплар кертергә.
5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына ел саен, 1 апрельгә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына План чараларын үтәү барышы турында мәгълүмат кертергә.
6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының җир асты байлыкларыннан, табигать ресурсларыннан файдалану һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре бүлегенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин